Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының егерме дүртенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы советы утырышы
КАРАРЫ

2019 елның 11 феврале № 182

2018 елда Питрәч муниципаль районының социаль-икътисадый
үсеш йомгаклары һәм 2019 елга бурычлар турында

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашаповныц «Питрәч муниципаль районының 2018 елда социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлар турында» отчетын тыңлап фикер алышканнан соц, Питрәч муниципаль районы Советы хисап чорында районның җирле үзидарә органнары икътисадны һәм социаль өлкәне тотрыклы үстерүгә, тормышны тәэмин итүнец барлык системаларыныц тотрыклы эшчәнлегенә, халыкның лаеклы тормыш дәрәҗәсен тәэмин итүгә, милләтара, конфессияара һәм гражданлык татулыгын ныгытуга, җирле үзидарә үсеше өчен шартлар булдыруга юнәлдерелгән эзлекле эш башкаруын билгеләп үтте.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, районның алга таба нәтиҗәле социаль-икътисадый үсеше, 2019 елга бурычларын уңышлы гамәлгә ашыру максатыннан **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашаповның «Питрәч муниципаль районыныц 2018 елдагы социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2019 елга бурычлары турында» гы отчетын игътибарга алырга.

2. Питрәч муниципаль районы Советы депутатларына «Питрәч муниципаль районының 2018 елда социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2019 елга бурычлары турында» гы район башлыгының хисабын үз округларындагы сайлаучылар игътибарына җиткерергә.

**3. Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына тәэмин итәргә:**

3.1. 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру буенча, беренче чираттагы чаралар планын 2019 елда үтәүне (алга таба – Стратегия);

3.2. 2019 елда Стратегия кысаларында төп макроикътисади күрсәткечләр нәтиҗәләрен үтәүне:

- тулай территориаль продуктка - 9906 млн. сум;
- тулай территориаль продукт алуда кече һәм урта бизнес өлеше - 39 %;
- төп капиталга инвестицияләр күләме - 10 млрд. сум;
- җан башына 20 мец сум акча кереме;
- уртача айлык хезмәт хакы - 31 мең сум;

3.3. 2019 елда Стратегия кысаларында төп нәтиҗәләрне гамәлгә ашыру өчен:

**3.3.1. планлаштыру һәм икътисадый үсеш өлкәсендә:**

- районга инвестицияләр җәлеп итү;
- эшкуарларга булган бизнесны башлау һәм үстерүдә җиңелрәк булган шартлар тудыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирү өчен муниципаль милек реестрын актуаль хәлдә тоту;
- авылда авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү һәм сату буенча кулланучылар кооперациясен (кимендә 2 кооператив) төзү;
- бюджетка салым һәм салым булмаган керемнәрнең даими мониторингын тормышка ашыру, салым органнары белән берлектә салымнарны вакытында түләүне оештыру буенча оператив чаралар күрү;
- товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алуларның нәтиҗәлелеген арттыру, коррупцияне һәм башка явыз ниятләрдән файдалануны булдырмау максатында, мондый сатып алуларның ачыклыгын тәэмин итү;
- бюджет учреждениеләре тарафыннан бюджет акчаларын экономияле файдалану буенча, бигрәк тә энергия чыганаклары чыгымнарында эш алып бару;
- бюджет законнарын үтәп, консолидацияләнгән бюджетның сыйфатлы үтәлешен тәэмин итү;
- муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен файдалануның нәтиҗәлелеген, шулай ук муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен район мәнфәгатьләрендә арендага бирүнең нәтиҗәлелеген арттыру;

**3.3.2. авыл хуҗалыгы өлкәсендә:**

- игенчелек һәм терлекчелектә алдынгы технологияләр кертү буенча чараларны дәвам итү;
- эре мөгезле терлекләрнең баш саны 3% ка үсешкә ирешү;
- сөт җитештерүне 3% ка арттыру;
- бер сыердан савымны елына 5 мең килограммга җиткерү;
- авыл хуҗалыгы предприятиеләренең матди базасын ныгыту, федераль һәм республика максатчан программаларында катнашу аша терлекләрнең баш санын арттыру буенча чаралар күрү;
- яңа эш башлаган һәм үсеп килүче крестьян-фермер хуҗалыкларына һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга, гаилә фермаларына ярдәм итү;
- фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясен базарга этәрү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыру;
- чәчүлек мәйданнарын саклау, сыйфатлы орлык материалы белән тәэмин итү, төрле ашламалар кертү һәм бөртекле культураларның уңдырышлылыгын гектардан 28 центнердан да ким булмаган уңыш алу буенча чаралар күрү;
- районның агросәнәгать комплексында җитештерүнең 3 проценттан да ким булмаган рентабельлегенә ирешү.
- 2019-2023 елларга Питрәч муниципаль районы территориясендә агросәнәгать комплексын үстерү буенча муниципаль программаны 2019 елның 1 апреленә кадәр эшләү һәм кабул итү;

**3.3.3. төзелеш һәм ТКХ өлкәсендә:**

- торак төзелеше, социаль-мәдәни өлкә объектлары, күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау, газлаштыру, су белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү программаларын сыйфатлы тормышка ашыруны тәэмин итү;

- юл катламнарын яхшырту, гамәлдәге юл челтәрен ремонтлау эшен дәвам итү;

- конңессион килешү буенча хезмәт күрсәтүче компанияләргә барлык инженерлык челтәрләрен тапшыруны тәэмин итү;

- торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне җыюның кимендә 100 % ка ирешү;

**3.3.4. мәгариф өлкәсендә:**

- 3 яшьтән өлкәнрәк барлык мохтаҗ балаларны мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урыннар белән тәэмин итү буенча эшне дәвам итү;

- укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең сәламәтлеген саклау өлешендә белем бирү мохитен куркынычсыз һәм белем бирү учреждениеләренә федераль таләпләрне үтәүне тәэмин итә торган шартлар тудыру;

- фән кабинетларын лаборатория җиһазлары белән тәэмин итү өлешендә мәгариф оешмаларының матди-техник базасын ныгыту буенча эшне көчәйтү;

- укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру буенча эшне активлаштыру;

- белем алучы шәхеснең иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен балаларга өстәмә белем бирү системасын үстерү;

**3.3.5. сәламәтлек саклау өлкәсендә:**

- поликлиникада «Дустанә поликлиника – Татарстан стандарты» кебек заманча пациентка юнәлдерелгән технологияләр кертү;

- халыкны канәгатьләндерә торган медицина хезмәтләренең сыйфатын арттыру;

- район халкын диспансерлаштыру һәм бигрәк тә авыруларның югары куркынычы булган гражданнар категориясен профилактик карау эшен дәвам итү;

- сабыйлар һәм аналар үлеме очракларына юл куймау;

- йөрәк-кан тамырлары, онкология авыруларын иртә ачыклау буенча чаралар комплексын үткәрү һәм шуның нәтиҗәсендә әлеге авырулардан үлүчеләр санын киметүгә ирешү;

- сәламәтлек саклау учреждениеләрен квалификацияле медицина кадрлары белән тәэмин итү буенча чаралар күрү;

- 2019 елда прививка компаниясенә 50% тан да ким булмаган күләмдә ирешү, халыкны грippка каршы вакцинацияләү белән колачлау;

- район халкын дару белән тәэмин итүне контрольгә алу;

**3.3.6. яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә:**

- яшьләр арасында эшче һөнәрләр буенча һөнәри осталык конкурслары үткәрү;

- физик культура белән системалы шөгыльләнүгә күбрәк кешеләрне җәлеп итү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

- булган спорт базасыннан нәтиҗәле файдалану, аның максималь йөкләнешен тәэмин итү;

- «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормаларын тапшыру буенча чаралар планын тулысынча үтәүне тәэмин итү;

**3.3.7. мәдәният өлкәсендә:**

- традицион халык һәм заманча мәдәниятне саклауны һәм үстерүне тәэмин итәү;

- ТАССР төзелүнең 100 еллыгына багышланган чараларны эзлекле рәвештә үткәрү;

- мәдәниятне, музей эшен һәм киноны үстерүгә юнәлдерелгән конкурсларда һәм ГРАНТларда актив катнашу;

**3.3.8. дин, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:**

- күчемсез милек объектларына дини оешмаларга милек хокукын рәсмиләштерүдә чаралар комплексын тормышка ашыру һәм ярдәм итү;

- дини оешмаларның иҗтимагый коммерцияле булмаган оешмалар өчен грантларда һәм конкурсларда катнашуы буенча эшне хәбәр итү һәм координацияләү;

- чаралар комплексын, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглауны һәм бәяләүне үткәрү;

- район территориясендә рухи яңарышны торгызуда ярдәм итү.

**4. Авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:**

- җирлек Советы утырышларында Питрәч муниципаль районы башлыгының отчеты буенча фикер алышу;

- район халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү буенча эшне дәвам итү;

- шәхси ярдәмче хуҗалыкларда терлекләрнең баш санын 2018 ел дәрәҗәсенә карата саклауны һәм 2% ка үстерүне тәэмин итү;

- шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү һәм аларга ярдәм итү республика программаларында катнашу буенча халык белән эшне көчәйтү;

- 2018 елның 18 ноябрендә районның авыл җирлекләре территориясендә уздырылган үзара салым кертү турында референдумда кабул ителгән акчаларны вакытында җыюны һәм кабул ителгән мәсьәләләрнең үтәлешен тәэмин итү;

- муниципаль районның җирле үзидарә органнарына, хокук саклау органнарына хокук бозуларны профилактикалау, терроризмга каршы тору һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм абруен ышанычлы яклауны тәэмин итүдә, авыл җирлекләре территориясендә яшәүче мигрантларның милләтара һәм конфессияара татулыгын ныгытуда, социаль һәм мәдәни җайлашуда ярдәм күрсәтү;

- торак пунктларны, зиратларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, җирлек территорияләрендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча актив эшләү.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Питрәч муниципаль районы Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1633605407